КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 17 март г.Казань № 153

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 498 нче; 2016 ел, 8 май, 287 нче; 2016 ел, 18 июнь, 413 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 705 нче; 2019 ел, 8 февраль, 82 нче; 2020 ел, 10 февраль, 84 нче; 2021 ел, 8 июнь, 441 нче; 2022 ел, 19 февраль, 138 нче; 2022 ел, 14 декабрь, 1324 нче; 2023 ел, 16 март, 260 нчы; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 3 июль, 779 нчы; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 19 декабрь, 1645 нче; 2024 ел, 13 февраль, 76 нчы; 2024 ел, 25 май, 365 нче; 2024 ел, 2 август, 614 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктның җиденче абзацында татар текстында «медицина» сүзе алдына «тернәкләндерү,» сүзен өстәргә;

3.4 пунктта «2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы» сүзләрен «2024 елның 23 декабрендәге 1873 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 5 бүлек өстәргә:

| «5. Тернәкләндерү ярдәме күрсәтүдә булышлык итү | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.1. | Тернәкләндерү хезмәтләреннән файдалануда ярдәм күрсәтү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрдән гыйбарәт: тернәкләндерү индивидуаль программалары нигезендә тер- | 0, 1, 2, 3 | хезмәтләр | кирәк булуга карап | социаль хезмәт күрсәтү чорында». |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | нәкләндерү чараларын үткәрүдә ярдәм күрсәтү;<br>табиблар бәяләмәләре буенча дару чаралары һәм медицина билгеләнешендәге эшләнмәләр алуда ярдәм күрсәтү;<br>шифаханә-курорт дәвалануына ташламалы юлламалар алуда ярдәм күрсәтү; протез-ортопед ярдәменнән файдалануда, шулай ук карау һәм тернәкләндерү өчен техник чаралар белән тәэмин итүдә булышлык итү | | | | |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 894 нче; 2017 ел, 30 декабрь, 1133 нче; 2019 ел, 16 февраль, 111 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 774 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 923 нче; 2020 ел, 14 апрель, 285 нче; 2020 ел, 30 июнь, 548 нче; 2020 ел, 16 июль, 600 нче; 2020 ел, 3 сентябрь, 779 нчы; 2021 ел, 15 февраль, 82 нче; 2021 ел, 5 май, 309 нчы; 2021 ел, 8 июнь, 442 нче; 2021 ел, 16 август, 731 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2021 ел, 22 ноябрь, 1109 нчы; 2022 ел, 3 февраль, 81 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1047 нче; 2022 ел, 31 октябрь, 1159 нчы; 2022 ел, 20 декабрь, 1375 нче; 2023 ел, 24 февраль, 182 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 4 сентябрь, 1067 нче; 2023 ел, 19 октябрь, 1323 нче; 2023 ел, 11 декабрь, 1599 нчы; 2023 ел, 19 декабрь, 1645 нче; 2024 ел, 31 гыйнвар, 50 нче; 2024 ел, 13 февраль, 76 нчы; 2024 ел, 25 май, 365 нче; 2024 ел, 2 август, 614 нче; 2024 ел, 28 сентябрь, 840 нчы; 2024 ел, 4 декабрь, 1093 нче; 2025 ел, 1 февраль, 56 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1.1 пунктның таблицасында:

5 пунктның 2 графасына «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

20 пунктның 2 графасында «2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы» сүзләрен «2024 елның 23 декабрендәге 1873 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

3.1.1 пунктның таблицасында:

6 пунктның 2 графасына «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

20 пунктның 2 графасында «2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы» сүзләрен «2024 елның 23 декабрендәге 1873 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

5.1.1 пункт таблицасының 10 пунктындагы 2 графасында «2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы» сүзләрен «2024 елның 23 декабрендәге 1873 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

7.1.1 пунктның таблицасында:

4 пунктның 2 графасына «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

10 пунктның 2 графасында «2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы» сүзләрен «2024 елның 23 декабрендәге 1873 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

8.1.1 пунктның таблицасында:

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

9 пунктның 2 графасында «2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы» сүзләрен «2024 елның 23 декабрендәге 1873 номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче; 2019 ел, 25 февраль, 125 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 775 нче; 2020 ел, 2 апрель, 250 нче; 2020 ел, 6 июль, 555 нче; 2021 ел, 21 апрель, 268 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2022 ел, 12 декабрь, 1316 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1493 нче; 2023 ел, 1 март, 195 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 13 июль, 823 нче; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 23 август, 1003 нче; 2023 ел, 31 август, 1054 нче; 2023 ел, 4 сентябрь, 1067 нче; 2023 ел, 10 октябрь, 1293 нче; 2023 ел, 11 декабрь, 1599 нчы; 2023 ел, 19 декабрь, 1645 нче; 2024 ел, 13 февраль, 76 нчы; 2024 ел, 25 май, 365 нче; 2024 ел, 8 июль, 537 нче; 2024 ел, 2 август, 614 нче; 2024 ел, 4 декабрь, 1093 нче; 2025 ел, 1 февраль, 56 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1.1 пункт таблицасының 8 пунктындагы 2 графасында «2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы» сүзләрен «2024 елның 23 декабрендәге 1873 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

3.1.1 пункт таблицасының 12 пунктындагы 2 графасында «2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы» сүзләрен «2024 елның 23 декабрендәге 1873 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

6.1.1 пункт таблицасының 8 пунктындагы 2 графасында «2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы» сүзләрен «2024 елның 23 декабрендәге 1873 номер-

лы» сүзләренә алмаштырырга;

7.1.1 пункт таблицасының 8 пунктындагы 2 графасында «2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы» сүзләрен «2024 елның 23 декабрендәге 1873 номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү турында» 2022 ел, 19 декабрь, 1366 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 21 ноябрь, 1032 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.3 пунктның беренче абзацында татар текстында «медицина» сүзе алдына «тернәкләндерү,» сүзен өстәргә;

әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 5 бүлек өстәргә:

| «5. Тернәкләндерү ярдәме күрсәтүдә булышлык итү | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5.1. | Тернәкләндерү хезмәтләреннән файдалануда ярдәм күрсәтү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>тернәкләндерү индивидуаль программалары нигезендә тернәкләндерү чараларын үткәрүдә ярдәм күрсәтү;<br>табиблар бәяләмәләре буенча дару чаралары һәм медицина билгеләнешендәге эшләнмәләр алуда ярдәм күрсәтү;<br>шифаханә-курорт дәвалануына ташламалы юлламалар алуда ярдәм күрсәтү;<br>протез-ортопед ярдәме алуда, шулай ук карау һәм тернәкләндерү өчен техник чаралар белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү | хезмәтләр | кирәк булуга карап | социаль хезмәт күрсәтү чорында». |

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2024 елларда «Психик бозылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү» пилот проектын

гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 18 июль, 860 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 1 март, 104 нче; 2024 ел, 29 ноябрь, 1083 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2023 – 2026 елларда коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибендә:

5.3 пунктның беренче абзацында татар текстында «медицина» сүзе алдына «тернәкләндерү,» сүзен өстәргә;

әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 5 бүлек өстәргә:

| «5. Тернәкләндерү ярдәме күрсәтүдә булышлык итү | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5.1. | Тернәкләндерү хезмәтләреннән файдалануда ярдәм күрсәтү | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрдән гыйбарәт: тернәкләндерү индивидуаль программалары нигезендә тернәкләндерү чараларын үткәрүдә ярдәм күрсәтү; табиблар бәяләмәләре буенча дару чаралары һәм медицина билгеләнешендәге эшләнмәләр алуда ярдәм күрсәтү; шифаханә-курорт дәвалануына ташламалы юлламалар алуда ярдәм күрсәтү; протез-ортопед ярдәме алуда, шулай ук карау һәм тернәкләндерү өчен техник чаралар белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү | хезмәтләр | кирәк булуга карап | социаль хезмәт күрсәтү чорында»; |

әлеге карар белән расланган 2023 – 2026 елларда психик бозылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны

финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

2.4 пунктта «шартнамәләр» сүзеннән соң «(килешүләр)» сүзен өстәргә;

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү Вәкаләтле орган тарафыннан, заявкаларны кабул итү төгәлләнгән дата җиткәнгә кадәр, түбәндәге шартларны үтәп гамәлгә ашырыла:

заявкаларны бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр керткәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә сайлап алуда катнашучыларның заявкага үзгәрешләр кертү хокукы каралган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.»;

3.15 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.17 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, үзгәрешләр кертү сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге беркетмәнең яңа версиясен булдыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең беренче версиясенә имза куелган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

5.10 пунктның икенче абзацында «шартнамәләр» сүзеннән соң «(килешүләр)» сүзен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин